ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«26» декабря 2023 ел № 403

«2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 06.04.2023 елның 77 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«2019-2025 елларга Татарстан Республикасында физик культураны һәм спортны үстерү» дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 05.03.2019 елның 159 номерлы карары, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү максатларында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 24.11.2020 елның 3081-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган 2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясендә физик культураны һәм спортны үстерү стратегиясе нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 06.04.2023 елның 77 номерлы карары белән расланган «2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 6 бүлек. 2023-2025 елларга Әгерҗе муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү чараларын 6.6 пункт белән тулыландырырга

| **№** | **Чараларның эчтәлеге** | **Үтәү срогы** | **Үткәрү өчен җаваплы** | **Финанслау күләме (мең сум)** | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | **2023** | **2024** | **2025** |
| 6.6 | Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче яшь белгечләргә акчалата түләүләрне гамәлгә ашыруга Татарстан | 2023ел | Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Спорт мәктәбе» ӨББ МБУ | 2,8 | 0 | 0 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертларны бүлү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 14.02.2023 елның 395-р номерлы күрсәтмәсе белән расланды | | | | | |

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына «Физик культура һәм спорт» тармаклары буенча каралган бюджет чаралары кысаларында муниципаль программа чараларын гамәлгә ашыруга бюджет акчалары бүлеп бирүне тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Г.Ф. Җәметовага йөкләргә.

**Җитәкчесе** **И.Х. Салихов**